**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2780**
**30.05.2019**

Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ санлы Законы, Башкарма комитетның Җитәкчесенең «Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында» 2008 елның 8 апрелендәге 428 нче боерыгы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Төзүченең һәм декларация проектының «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 7863 нче карары үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (parvo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2019 елның 30 маендагы
2780 нче карарына
кушымта

Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы булып түбәндәгеләр тора:

а) өлешләп төзү объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган һәм «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 15.4 маддәсендә каралган тәртиптә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары проект декларациясе нигезендә эскроу счетларында урнаштырылмаган очракта:

- төзүчеләр – оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, милкендә яки аренда хокукында, субаренда хокукында яисә «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ санлы Федераль законда (алга таба – «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль закон), Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пунктының 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукындагы җир участогы булган һәм төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә әлеге җир участогында, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче юридик затлар;

б) өлешләп төзү объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган һәм «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 15.4 маддәсендә каралган тәртиптә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары проект декларациясе нигезендә эскроу счетларында урнаштырылмаган очракта:

төзүчеләр – хуҗалык җәмгыятьләре:

төзүче, һәм (яки) техник заказчы сыйфатында, һәм (яки) генераль подрядчы сыйфатында төзелеш подрядының килешүе нигезендә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә шундый күп фатирлы йортларны файдалануга тапшыруга

алынган рөхсәтләре булган очракта, барлыгы гомуми мәйданы биш мең квадрат метрдан ким булмаган күп фатирлы йортларны төзүдә (булдыруда) катнашу тәҗрибәсе булган (өч елдан да ким булмаган) төп җәмгыятьләр яисә төп җәмгыятьләрнең теләсә кайсы бүлендек хуҗалык җәмгыятьләре;

милкендә яки аренда хокукында, субаренда хокукында яисә «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ санлы Федераль законда (алга таба – «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль закон), Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пунктының 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукындагы җир участогы булган һәм төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә әлеге җир участогында, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүчеләр;

исемендә «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

в) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 15.4 маддәсендә каралган тәртиптә эскроу счетына кертелгән очракта:

төзүчеләр – хуҗалык җәмгыятьләре:

милкендә яки аренда хокукында, субаренда хокукында яисә «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ санлы Федераль законда (алга таба – «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль закон), Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пунктының 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукындагы җир участогы булган һәм төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә әлеге җир участогында, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүчеләр;

исемендә «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

1.3. Дәүләт хезмәте Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Бүлекнең урнашу урыны: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 109 кабинет.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр.

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Белешмә өчен телефоннар: 30-56-80, 30-56-81.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты адресы: (http://www.nabchelny.ru).

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) күрсәтелгән дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматларны үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru) аша;

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) аша;

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша;

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта (электрон почта адресы – goscontrol@list.ru) аша электрон рәвештә.

1.4 Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005, №1, ст. 40);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, ст. 4179);

- Россия Федерациясе Җир кодексы, 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – Җир кодексы) («РФ законнар җыентыгы», 29.10.2001, №44, ст. 4147).

- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Законы (Республика Татарстан, №155-156, 03.08.2004);

- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ санлы Законы (алга таба – 66-ТРЗ санлы ТР Законы) («Республика Татарстан», №259, 28.12.2007);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасы сайтының адресын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 1133 нче Карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1133 нче Карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.10.2018, №40, ст. 6137);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгы нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 нче карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1683 нче карары) (РФ законнар җыентыгы, 31.12.2018, №53 (II бүлек), ст. 8712);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе формасын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр санлы приказы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр санлы приказы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 30.12.2016, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, басылып чыгу номеры: 0001201612300099);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез

милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә формасын раслау хакында» 2018 елның 11 октябрендәге 653/пр санлы Приказы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 653/пр санлы Приказы) Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 28.12.2018, басылып чыгу номеры: 0001201812280059);

- Федераль финанс базарлары хезмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативларын исәпләү тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 2006 елның 30 ноябрендәге 06-137/пз-н санлы приказы (алга таба – Федераль финанс базарлары хезмәтенең 06-137/пз-н санлы приказы) (Российская газета, 31.01.2007, №19);

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав) («Челнинские известия №235-237, 10.12.2005, «Челнинские известия» №249-250, от 30.12.2005);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре);

- Башкарма комитетның 2018 елның 24 октябрендәге 6345 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты (алга таба – Эш регламенты) («Челнинские известия», №90, 12.12.2018) карар, регламент (1-5 бүлекләр (башы)), «Челнинские известия», №93, 21.12.2018 (5 бүлек (ахыры) - 7, 1-4 кушымталар);

- Башкарма комитетның 2008 елның 8 апрелендәге 428 нче боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге турында нигезнамә (алга таба – Бүлек турында нигезнамә);

- Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш реламенты);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар, билгеләмәләр, кыскартулар кулланыла:

- гариза бирүчеләр – әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән төзүчеләр (аларның вәкаләтле вәкилләре);

- Бүлек – дәүләт хезмәтен башкаручы булып торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге;

- вәкаләтле банк – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән һәм Россия Банкы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга туры килә торган банклар исемлегенә кертелгән банк. Россия Банкы ай саен банкларның күрсәтелгән исемлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштыра;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

## 2 бүлек. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең исеме | Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү | 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсе 6 бүлегенең 1.2 пунктчасы;<br>66-ЗРТ санлы ТР Законының 1 маддәсе |
| 2.2. Турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-идарә итү органының исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге йөзендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | Шәһәр Уставы,<br>Бүлек турында нигезнамә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсендәге 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә (алга таба – туры килү турында бәяләмә) бирү (2 нче кушымта) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат | 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсе 6 бүлегенең 1.2 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сроклары, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктату мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатуның срогы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан проект декларациясе алынган көннән башлап 30 календарь көн.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы каралмаган.<br><br>Гариза бирүчегә әлеге Регламентның 2.9 пунктында билгеләнгән нигезләр буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, яисә гариза бирүчегә андый бәяләмә бирелгән көннән башлап 60 көн эчендә аның тарафыннан документлар күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектын өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән килешү дәүләт теркәвенә бирелмәсә, проект декларациясе, әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кабаттан җибәрелергә тиеш. | 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе 2.1 һәм 2.3 бүлекләре |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) Дәүләт хезмәте күрсәтү турында Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә язылган гариза, 1 нче кушымтада каралганча;<br>2) Юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе;<br>3) Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать итсә);<br>4) Проект декларациясе (Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр санлы боерыгында билгеләнгән форма буенча), 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.2 маддәсенең 4 бүлегендә күрсәтелгән физик затның күрсәтелгән маддә таләпләренә туры килүе турындагы мәгълүмат, төзүченең күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектын өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән килешү төзегәнгә кадәр, төзүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең (https://наш.дом.рф/) 214-ФЗ санлы Федераль законның 23.3 маддәсендә күрсәтелгән торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасы сайтында проект декларациясен электрон рәвештә тутырып Башкарма комитетка җибәрелә. | 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2 бүлеге; РФ Хөкүмәтенең 1133 нче карары |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, | Ведомствоара үзара эшчәнлек кысаларында түбәндәге документлар алынырга мөмкин:<br><br>- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (мәгълүматлар); | 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2.1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тапшырырга тиешле норматив хокукый актлар нигезендәге кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | - гариза бирүченең салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында мәгълүматлар (белешмә);<br><br>- аерым затның аның күчемсез милек объектларына булган хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә.<br><br>- гариза бирүче тарафыннан объект төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган җир участогына карата Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (мәгълүматлар);<br><br>- төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органының функцияләрен гамәлгә ашыручы затның, һәм төзүченең баш бухгалтерының яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи затның, яисә төзүченең бухгалтерлык исәбен алып бару буенча хезмәт күрсәтү турында килешү төзелгән затның икътисад өлкәсендәге җинаятьләре өчен хөкем ителмәгән булуы турында мәгълүматлар;<br><br>- төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органының функцияләрен гамәлгә ашыручы затның, һәм төзүченең баш бухгалтерының яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи затның, яисә төзүченең бухгалтерлык исәбен алып бару буенча хезмәт күрсәтү турында килешү төзелгән затның хөкем ителү срогы чыкмаган булу турында мәгълүматлар.<br><br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы документларны, шулай ук, 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсенең 1 бүлеге 4 пунктының «а» - «г» пунктчаларында саналган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда дәүләт хезмәте | 1) Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге | Эш регламенты |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен килешенү таләп ителгән очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган дәүләт органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 2) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе<br>3) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу.<br>2) Тапшырылган документлар Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү.<br>3) Гаризада һәм аңа теркәлгән документларда алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирми торган җитди бозулар булу. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | - төзүченең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>- төзүче проекты декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>- 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә төзүче һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки андый төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте тарафыннан проект декларациясе җибәрелгән датага төзүченең шундый күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырылган проект декларациясендә күрсәтелгән өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыру срогы төзүче тарафыннан өч һәм аннан күбрәк айга бозылган очракта. | 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2.2 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезлелеге | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезлелеге, андый түләү күләменең исәп-хисап методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза Башкарма комитетка кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.<br>Проект декларациясе «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасы сайтына (https://наш.дом.рф/) кертелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә. | РФ Хөкүмәтенең 1133 нче карары |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән күрсәтелгән объектларны Россия Федерациясенең | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга дәүләт хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү). | |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә тәэмин итү, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикле инвалидларны да истә тотып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлегенең саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документлар кабул итү һәм бирү гамәлгә ашырыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләр булу;<br>3) Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>4) мөмкинлекләре чикле кешеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү);<br>5) инвалидларга башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу срогын үтәү;<br>3) гариза бирүчеләрнең документларын кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар булмау;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның эш итүенә (эш итмәвенә) шикаятьләр булмау;<br>5) инвалидларга башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи | |

| | | |
|---|---|---|
| | затның һәм гариза бирүченең бер генә тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү күпфункцияле үзәк аша, ул дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат Бүлек башлыгына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән телефон аша), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Башкарма комитетның рәсми сайтында (http://www.nabchelny.ru) алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтүнең үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы консультацияне электрон формада Интернет-кабул итү яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин. Әгәр законда дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештә гариза бирү каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/) бирелә. | |

## 3 бүлек. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- гариза бирүчегә консультация бирү;

- туры килү турында бәяләмә яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат әзерләү һәм бирү (җибәрү);

- техник хаталарны (язудагы хаталарны, басмадагы хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү.

3.2.1. Гариза бирүченең дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә телдән (шәхсән яки телефон буенча) яисә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгате административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча.

Гариза бирүченең телдән мөрәҗәгатенә җавап гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Граждан мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга теләгән очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә язмача консультация бирүне гамәлгә ашыра, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча.

Язмача мөрәҗәгатькә җавап – мөрәҗәгать теркәлгән датадан башлап утыз календарь көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Туры килү турында бәяләмә яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат әзерләү һәм бирү (җибәрү).

3.3.1. Туры килү турында бәяләмә бирү яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны (мәгълүматны) теркәү;

2) гаризаны карап тикшерү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру (җибәрү) һәм һәркем файдалана алырлык сайтлардан мәгълүмат алу;

4) туры килү турында бәяләмә яисә туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат формалаштыру;

5) туры килү турында бәяләмә яки туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат бирү (җибәрү).

3.3.2. Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны (мәгълүматны) теркәү.

Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) Регламентка

1 нче кушымтада каралган форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.2.1. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- гариза бирүченең шәхесен билгели;
- гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);
- әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар булуны тикшерә;
- тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызган сүзләр һәм башка алдан килешенмәгән төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- гаризаларны кабул итә һәм бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында терки;
- гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризаларны кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

- гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;
- гаризаны теркәү гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза, документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Гаризаны карап тикшерү.

Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны, документларны карап тикшерә һәм гаризаны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләр төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгына (алга таба – бүлек башлыгы) җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.3.1. Бүлек башлыгы гаризаны, документларны карап тикшерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерелгән, әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга һәм оешмаларга ведомствоара запрослар формалаштыру (җибәрү) һәм һәркем файдалана алырлык сайтлардан мәгълүмат алу

3.3.4.1. Бүлек белгече, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге буенча мәгълүматлар алу өчен, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарга, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарга, дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы ведомство буйсынуындагы дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына ведомствоара запрослар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан башлап биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында җибәрелгән запрослар.

3.3.4.2. Бүлек запрослары буенча хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан автоматлаштырылган режимда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

запросны эшкәртү һәм эзләү соралган мәгълүматларны эзләү;

ведомствоара электрон хезмәттәшлек аша соралган мәгълүматларны формалаштыру яисә соралган мәгълүматлар булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соралган мәгълүматларны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар законда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүматлар) яисә мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.3.4.3. Бүлек белгече һәркем файдалана алырлык сайтлардан төзүчегә – юридик затка карата электрон рәвештә мәгълүмат ала:

Россия Федераль салым хезмәте сайтында egrul.nalog.ru – ликвидация процедурасы булу (булмау) турында;

Россия Федерациясе арбитраж судлары сайтында kad.arbitr.ru – банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында, эшчәнлекне административ җәза чарасы буларак туктатып тору турында карар булу (булмау);

сатып алулар өлкәсендә Бердәм мәгълүмат системасы сайтында old.zakupki.gov.ru – алып бару «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында мәгълүматлар булу (булмау) турында;

Россия Федераль монополиягә каршы хезмәте сайтында rnp.fas.gov.ru - алып бару «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турынд» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында мәгълүматлар булу (булмау) турында;

сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясе сайтында torgi.gov.ru – җир участогын сату буенча аукционда яисә җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүматлар булу (булмау) турында.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан башлап биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: һәркем файдалана алырлык сайтлардан алынган мәгълүмат.

3.3.5. Туры килү турында бәяләмә яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат формалаштыру

3.3.5.1. Әлеге Регламентның 3.3.4 пунктында каралган административ гамәлләрнең нәтиҗәләре административ гамәлне башлау өчен нигез булып тора.

Бүлек белгече:

әлеге Регламентның 3.3.4 пункты нигезендә һәркем файдалана алырлык сайтлардан һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган документларны (мәгълүматны) карап ткшерүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра;

торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәхси кабинетына (https://наш.дом.рф/) җибәрелгән гариза бирүченең проект декларациясендәге мәгълүматның 2140ФЗ санлы Федераль законның 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килү фактын билгели;

гариза бирүченең түбәндәгеләр нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килү фактын билгели:

1) гариза бирүче әлеге Регламентның 1.2 пунктының «а» пунктчасына туры килгән очракта, 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләре нигезендә (218-ФЗ санлы Федераль закон, 175-ФЗ санлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча);

2) гариза бирүче әлеге Регламентның 1.2 пунктның «б» пунктчасына туры килгән очракта, 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1, 2 бүлекләре нигезендә;

3) гариза бирүче әлеге Регламентның 1.2 пунктының «в» пунктчасына туры килгән очракта, 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсе 2 бүлегенең 1, 2 – 6, 8 пунктлары нигезендә;

туры килү турында бәяләмә проектын яки туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм килешенү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Туры килү турында бәяләмә бирү хакында карар кабул ителгән очракта, Бүлек белгече тарафыннан әлеге бәяләмәне түбәндәге формаларда әзерләү гамәлгә ашырыла:

- төзүче тарафыннан күчемсез милек объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта, әлеге Регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча;

- төзүче тарафыннан күчемсез милек объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта, әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча;

- өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары эскроу счетларына урнаштырылган очракта, әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.3.4 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамланган вакыттан башлап җиде календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.2. Бүлек башлыгы карар проектын карап тикшерә, килешенә һәм аны килешенү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер календарь көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән, килешенү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.3. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы карар проектын карап тикшерә, килешенә һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә яисә карар проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм кимчелекләрне бетерү өчен әлеге күрсәтмәләрне Бүлек белгеченә җибәрә.

Процедураларның срогы: карар проекты Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә кергән вакыттан башлап ике календарь көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: килешенгән, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты яисә карар проектындагы кимчелекләр буенча Бүлек белгеченә җибәрелгән күрсәтмәләр.

3.3.5.4. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе тарафыннан карар проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, Бүлек белгече кимчелекләрне төзәтә һәм аны алга таба килешенү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: кимчелекле карар проекты Бүлеккә кергән вакыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның срогы: төзәтелгән һәм килешенү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.5. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе төзәтелгән карар проектын карап тикшерә һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: төзәтелгән карар проекты Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә кергән вакыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.6. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) ахыргы варианттагы карар проектын тикшерә;

2) карар проектын тарату реестрында Башкарма комитет вазыйфаи затларының кирәкле визалары булуны (булмауны) тикшерә;

3) карар проектын бастырып чыгара һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Процедураның срогы: әлеге регламентның 3.3.5.5 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан башлап 1 календарь көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.7. Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын имзалый, теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: әлеге регламентның 3.3.5.6 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.8. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гамәлгә ашыра:

1) имзаланган карар проектын Башкарма комитет Җитәкчесенең чыгучы хатлар Реестрында теркәүне;

2) карарны Бүлеккә җибәрүне.

Процедураның срогы: Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карар проекты имзаланган вакыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән карар.

3.3.6. Туры килү турында бәяләмәне яки туры килү турында бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хатны бирү (җибәрү)

3.3.6.1. Бүлек белгече гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән карарны бирү датасы һәм вакыты турында белдерә.

Процедураның срогы: әлеге регламентның 3.3.5.8 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү, рәсмиләштерелгән карарны бирү датасы һәм вакыты турында белдерү.

3.3.6.2. Бүлек белгече туры килү турында рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, туры килү турында бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хатны гариза бирүченең (аның вәкиленең) кулына тапшыра яки почта аша белдерү кәгазе булган хат белән җибәрә.

Башкарма комитет сайтында, шулай ук торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында туры килү турында бәяләмә бирү турында яки туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында мәгълүмат урнаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура әлеге Регламентың 3.3.5.8 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан башлап ике календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән карар.

3.4. Техник хаталарны (язудагы хаталарны, басмадагы хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү

3.4.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документ;

техник хата булуны раслый торган юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелә.

3.4.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза.

3.4.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны, документларны карап тикшерә һәм гаризаны Бүлек башлыгына җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланган вкыттан башлап 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4.4. Бүлек башлыгы гаризаны, документларны карап тикшерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерелгән һәм Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4.5. Бүлек белгече:

документларны карап тикшерә;

техник хаталар булмаган очракта, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турындагы карар проектын әзерли, аны килешенү өчен Бүлек башлыгына, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак үсеше идарәсе башлыгына, аннан соң имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында теркәлгән карарны Бүлек белгече гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) шәхсән бирә яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша (электрон почта аша) җибәрә;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатында, туры килү турында бәяләмә проектын яки шундый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли, әлеге Регламентның 3.3.5.7 пунктында каралган гамәлләрне гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкиленнән) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып, имза куйдырып, гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) кабат рәсмиләштерелгән документны шәхсән тапшыра яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша (электрон почта аша) техник хата булган документның төп нөсхәсен Башкарма комитетка алып килгән очракта документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата ачыкланганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән техник хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) карар.

## 4 бүлек. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килешенү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә үткәрелгән тикшерүләр;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр вакытында дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезнамәләрдә һәм Башкарма комитет хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралмавы өчен җаваплы.

Бүлек башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларның үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5 бүлек. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, КФҮнең, шулай ук КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар Башкарма комитетның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне

оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1. маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, КФҮнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы

бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәтеннән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Судка шикаять бирү.

Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Кемгә: ________________________________
________________________________________
Кемнән: ______________________________
оешманың һәм юридик затның оештыру-хокукый формасы исеме
_________________________________ йөзендә
(җитәкченең яки башка вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Элемтә мәгълүматы:
Тел. _________________________________
Электрон почтасы ___________________
Гариза бирүченең
(гариза бирүче вәкиленең)
почта адресы:
________________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында
гариза
«___» _______ 20__ ел.

«Күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсе нигезендә, «Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү» буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне сорыйм.

Проект декларациясе торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган (наш.дом.рф), № ______ __ ________.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат теркәлә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең ахыргы нәтиҗәсен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында шәхсән кулга тапшыруны һәм (яки) гаризада күрсәтелгән почта адресына җибәрүне сорыйм.

Теркәлә: (гариза бирүче тарафыннан тапшырылган барлык документларны һәм һәр документтагы битләр санын күрсәтергә):

____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________

Имза ____________________________________ ________________________________________
(имза расшифровкасы)

Дата ____________________

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Төзүченең һәм проект декларациясенең
«Күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә [1]

№ « __ » ________ 20____ ел

Төзүченең исеме: ____________________________________________
Төзүченең ОГРН: ____________________________________________
Төзүченең ИНН: ____________________________________________
Төзелеш проектының исеме: ____________________________________
____________________________________________________________
Капиталь төзелеш объектының адресы:[2] ____________________________
____________________________________________________________
Төзелешкә рөхсәтнең номеры ______________ бирү датасы ______________
бирелде______________________________________________________
(Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле башкарма хакимият органының
____________________________________________________________
яки төзелешкә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органының исеме)

Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүнең планлаштырылган ысулы:
____________________________________________________________
(өлешләп төзүдә катнашу килешүе/акчаларын эскроу счетларында урнаштырып өлешләп төзүдә катнашу килешүе)

Әлеге бәяләмә төзүченең ____________________________________
____________________________________________________________
өлешләп төзүдә катнашу килешүе нигезендә, күп катлы йорт(лар) һәм (яки) өч һәм аннан күбрәк блоктан торган блоклы төзелеш йортлары төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукын, шулай ук төзүченең һәм төзелеш проекты турында проект декларациясенең («___» ______________ 20 ___ ел редакциясендә)
____________________________________________________________
(төзелеш проектының исеме)
«Күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

---

[1] Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәне (алга таба – бәяләмә) кәгазьдә биргән очракта, бәяләмәдә бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызган сүзләр һәм төзәтүләр булырга тиеш түгел. Бәяләмә өлешләп төзү өлкәсендә контрольне (күзәтчелекне) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органының рәсми бланкында рәсмиләштерелә, шундый органның вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм мөһер белән раслана (булганда). Андый бәяләмә электрон рәвештә бирелгән очракта, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып имзалана.

[2] Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт нигезендә әлеге объектның адресы күрсәтелә.

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон нормаларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый. [3]

Төзүченең һәм проект декларациясенең күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүматлар ____ кушымтада күрсәтелгән [4].

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле
вазыйфаи зат ____________________________________________

(вазыйфаның исеме)

____________________________________________ ____________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

---

[3] Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005, №1, ст. 40; 2018, №31, ст. 4861.

[4] Бәяләмәгә өч кушымтаның берсе рәсмиләштерелә. Кушымтаны сайлау төзелешкә рөхсәт алу датасына (2018 елның 1 июленә кадәр/2018 елның 1 июленнән соң) яки өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүнең планлаштырылган ысулына бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

«___» ____________ 2019 ел №____
төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәгә
1 нче кушымта

Төзүче тарафыннан күчемсез милек объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта, төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүматлар[1]

| | Туры килү турында таләп | Туры килү турында билге[2] |
|---|---|---|
| 1 | Төзүченең устав (склад) капиталы, устав фонды тулысынча түләнгән һәм минималь күләмнән ким булмаган күләмдә тәшкил итә[3] | |
| 2 | Төзүчегә карата юридик затларны ликвидацияләү процедуралары үткәрелми | |
| 3 | Төзүчегә карата арбитраж судының банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турындагы карары булмау | |
| 4 | Төзүчегә карата арбитраж судының административ җәза чарасы буларак аның эшчәнлеген туктатып тору турындагы карары булмау | |
| 5 | Төзүчегә карата намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрларында[4] алар тарафыннан | |

[1] Кушымта төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары җәлеп ителгән күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзүгә рөхсәт төзүче тарафыннан 2018 елның 1 июленә кадәр алынган һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары эскроу счетларында урнаштырылмаган очракта рәсмиләштерелә.

[2] Графа «туры килә» форматында тутырыла.

[3] «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2.1 бүлегендә билгеләнгән (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005, №1, ст. 40; 2018, № 31, ст. 4861).

[4] Реестрларны алып бару «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, №14, ст. 1652; 2018, №32, ст. 5104) һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 30, ст. 4571; 2018, № 32, ст. 5135) нигезендә гамәлгә ашырыла.

| | | |
|---|---|---|
| | контрактларда яки килешүләрдә (предметы булып капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау өлкәсендә эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү яки мондый төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт оештыру яисә юридик заттан торак бүлмәләр сатып алу тора) каралган йөкләмәләрне үтәү өлешендә төзүче (шул исәптән төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат) турында мәгълүмат булмау | |
| 6 | Төзүчегә (шул исәптән төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы затка) карата дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын сату буенча аукционда яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүмат булмау[5] | |
| 7 | Төзүченең салымнар, җыемнар буенча недоимка, алдагы календарь ел өчен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча күләме соңгы хисап датасына, бурычлы затка – юридик затка карата таләпләрнең гомуми күләменә тигез яки аннан артып китә торган бурычлары булмау | |
| 8 | Төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы затның һәм төзүченең бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи затның, яисә төзүченең бухгалтерлык исәбен алып бару буенча хезмәт күрсәтү турында килешү төзегән затның икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен хөкем ителмәгән (мондый суд хөкеме үтәлгән яки бетерелгән затлардан тыш), шулай ук күрсәтелгән затларга карата, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү яки мондый төзелеш, реконструкция оештыру оешмаларын төзү өлкәсендә аерым вазыйфалар биләп тору яки аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү рәвешендәге җәза һәм дисквалификация рәвешендә административ җәза бирелмәгән булу | |
| 9 | Проект декларациясе җибәрелгән датага төзүченең шундый күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырылган проект декларациясендә күрсәтелгән өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыру срогын төзүче һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки андый төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте тарафыннан өч һәм аннан күбрәк айга бозу факты ачыкланмау[6] | |

[5] Реестрны алып бару Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 маддәсенең 28 һәм 29 пунктлары нигезендә (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2001, №44, ст. 4147; 2018, №32, ст. 5135) гамәлгә ашырыла.

[6] Проект декларациясе җибәргән датага шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә файдалануга тапшырылмаган күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары исәпкә алына.

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзүче турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә [7] | |
| 11 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзелеш проекты турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[7] | |

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле
вазыйфаи зат

________________________________________
(вазыйфаның исеме)

________________________________________ __________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)   (имза)

[7] «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән.

«___» ____________ 2019 ел №____
төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәгә
2 нче кушымта

Төзүче тарафыннан күчемсез милек объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта, төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүматлар[1]

| Туры килү турында таләп | | Туры килү турында билге[2] |
|---|---|---|
| 1 | Төзүче, төзелешкә бер рөхсәт кысаларында өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, төзелешне гамәлгә ашыра (гамәлгә ашырачак) | |
| 2 | Төзүче төзелешне җир участогының шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә, төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә яисә төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзүгә мөнәсәбәтле төзелгән территория яки территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү яки территорияне комплекслы үстерү турында килешү төзүгә мөнәсәбәтле территория чикләрендә урнашкан бер яки берничә җир участогында төзелеш өчен бер яки берничә рөхсәт чикләрендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашыра (гамәлгә ашырачак) | |
| 3 | Төзүченең проект документлары һәм проект документларына экспертизаның уңай бәяләмәсе бар | |
| 4 | Төзүченең шәхси акчалары төзелешнең проект бәясенең 10% ким булмаган күләмдә тәшкил итә | |
| 5 | Вәкаләтле банкта төзүченең банк счетында проект декларациясен җибәрү датасына төзелешнең проект бәясенең 10% нан ким булмаган күләмдә акчалары бар яисә күрсәтелгән датага төзүче вәкаләтле банк белән, составына өлешләп төзү объектлары керә торган күп фатирлы | |

[1] Кушымта төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары җәлеп ителгән күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзүгә рөхсәт төзүче тарафыннан 2018 елның 1 июленнән соң алынган һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары эскроу счетларында урнаштырылмаган очракта рәсмиләштерелә.

[2] Графа «туры килә» форматында тутырыла.

| | | |
|---|---|---|
| | йорт(лар)ны төзү өчен, вәкаләтле банк тарафыннан төзүчегә төзелешнең проект бәясенең 40% ким булмаган күләмдә максатчан кредит бирү турында килешү төзегән | |
| 6 | Төзүченең төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле максатчан кредитлардан һәм (яки) мондый займ буенча процентлар займ килешүе төзү датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының ике процент пунктка арттырылган төп ставкасыннан артмаган очракта, күрсәтелгән максатларга төзелеш өчен бирелгән рөхсәтләрнең һәркайсы буенча төзелешнең проект бәясенең 20% артмаган күләмдә төзүченең төп җәмгыяте тарафыннан бирелгән максатчан займнардан тыш, кредитлар, займнар, ссудлар буенча йөкләмәләре булмау | |
| 7 | Төзүче тарафыннан акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр чыгару яки бирү тормышка ашырылмаган | |
| 8 | Төзүченең өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле булмаган йөкләмәләре, өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органына проект декларациясен җибәрү датасына, төзелешнең проект бәясенең 1% тан артмый (төзүченең сыйфат гарантияләре кысаларында өлешләп төзү объектының (объектларның) кимчелекләрен бетерү буенча йөкләмәләреннән тыш) | |
| 9 | Төзүче карамагындагы мөлкәт өченче затларның йөкләмәләрен, шулай ук төзүченең төзелешкә бер рөхсәт яки төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә бәйле булмаган үз йөкләмәләрен тәэмин итү өчен файдаланылмый | |
| 10 | Төзүченең өченче затларның йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итү буенча йөкләмәләре булмау | |
| 11 | Төзүче финанс тотрыклылыгы нормативларын үти[3] | |
| 12 | Төзүчегә карата юридик затларны ликвидацияләү процедуралары үткәрелми | |
| 13 | Төзүчегә карата арбитраж судының банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турындагы карары булмау | |
| 14 | Төзүчегә карата арбитраж судының административ җәза чарасы буларак аның эшчәнлеген туктатып тору турындагы карары булмау | |

[3] «Күп фатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 1 июлендәге 75-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсенең 1 һәм 2 бүлекләре (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2018, №28, ст. 4139) нигезендә төзелешкә рөхсәтне 2018 елның 1 июленнән соң алган төзүчеләрнең финанс тотрыклылыгы нормативларын үтәү буенча бурычы 2018 елның 30 сентябреннән барлыкка килә.

| | | |
|---|---|---|
| 15 | Төзүчегә карата намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрларында[4] алар тарафыннан контрактларда яки килешүләрдә (предметы булып капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау өлкәсендә эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү яки мондый төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт оештыру яисә юридик заттан торак бүлмәләр сатып алу тора) каралган йөкләмәләрне үтәү өлешендә төзүче (шул исәптән төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат) турында мәгълүмат булмау | |
| 16 | Төзүчегә (шул исәптән төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы затка) карата дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын сату буенча аукционда яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүмат булмау[5] | |
| 17 | Төзүченең салымнар, җыемнар буенча недоимка, узган календарь ел өчен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча күләме соңгы хисап датасына бурычлы затка – юридик затка карата таләпләрнең гомуми күләменә тигез яки аннан артып китә торган бурычлары булмау | |
| 18 | Төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат, төзүченең коллегиаль башкарма органы әгъзасы булып торучы зат яки төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырган очракта, идарәче компаниянең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат яисә төзүченең вакытлыча бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы, ахыр чиктә турыдан – туры яки читләтеп (өченче затлар аша) (капиталда 5% тан артык катнаша) корпоратив юридик зат – төзүчегә хуҗа булган зат, төзүченең баш бухгалтеры «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.2 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килә[6] | |

[4] Реестрларны алып бару «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, №14, ст. 1652; 2018, №32, ст. 5104) һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 30, ст. 4571; 2018, № 32, ст. 5135) нигезендә гамәлгә ашырыла.

[5] Реестрны алып бару Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 маддәсенең 28 һәм 29 пунктлары нигезендә (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2001, №44, ст. 4147; 2018, №32, ст. 5135) гамәлгә ашырыла.

[6] Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005, №1, ст. 40; 2018, №31, ст. 4861.

| | | |
|---|---|---|
| 19 | Проект декларациясе җибәрелгән датага төзүченең шундый күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырылган проект декларациясендә күрсәтелгән өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыру срогын төзүче һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки андый төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте тарафыннан өч һәм аннан күбрәк айга бозу факты ачыкланмау | |
| 20 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзүче турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[7] | |
| 21 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзелеш проекты турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[7] | |

Бәяләмә биргүгә вәкаләтле
вазыйфаи зат ________________________________

(вазыйфаның исеме)

________________________________ ________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

[7] «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән.

«___» ____________ 2019 ел №____
төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәгә
3 нче кушымта

Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары эскроу счетларында урнаштырылган очракта, төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүматлар[1]

| Туры килү турында таләп | | Туры килү турында билге[2] |
|---|---|---|
| 1 | Төзүчегә карата юридик затларны ликвидацияләү процедуралары үткәрелми | |
| 2 | Төзүчегә карата арбитраж судының банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турындагы карары булмау | |
| 3 | Төзүчегә карата арбитраж судының административ җәза чарасы буларак аның эшчәнлеген туктатып тору турындагы карары булмау | |
| 4 | Төзүчегә карата намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрларында[3] алар тарафыннан контрактларда яки килешүләрдә (предметы булып капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау өлкәсендә эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү яки мондый төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт оештыру яисә юридик заттан торак бүлмәләр сатып алу тора) каралган йөкләмәләрне үтәү өлешендә төзүче (шул исәптән төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат) турында мәгълүмат булмау | |

[1] Кушымта өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары эскроу счетларында урнаштырылган очракта рәсмиләштерелә.

[2] Графа «туры килә» форматында тутырыла.

[3] Реестрларны алып бару «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, №14, ст. 1652; 2018, №32, ст. 5104) һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 30, ст. 4571; 2018, № 32, ст. 5135) нигезендә гамәлгә ашырыла.

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Төзүчегә (шул исәптән төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы затка) карата дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын сату буенча аукционда яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүмат булмау[4] | |
| 6 | Төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат, төзүченең коллегиаль башкарма органы әгъзасы булып торучы зат яки төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырган очракта, идарәче компаниянең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат яисә төзүченең вакытлыча бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы, ахыр чиктә турыдан – туры яки читләтеп (өченче затлар аша) (капиталда 5% тан артык катнаша) корпоратив юридик зат – төзүчегә хуҗа булган зат, төзүченең баш бухгалтеры «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.2 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килә[5] | |
| 7 | Проект декларациясе җибәрелгән датага төзүченең шундый күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырылган проект декларациясендә күрсәтелгән өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыру срогын төзүче һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки андый төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте тарафыннан өч һәм аннан күбрәк айга бозу факты ачыкланмау | |
| 8 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзүче турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[6] | |
| 9 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзелеш проекты турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[6] | |

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле
вазыйфаи зат ______________________________

(вазыйфаның исеме)

______________________________ ______________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

---

[4] Реестрны алып бару Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 маддәсенең 28 һәм 29 пунктлары нигезендә (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2001, №44, ст. 4147; 2018, №32, ст. 5135) гамәлгә ашырыла.

[5] Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005, №1, ст. 40; 2018, №31, ст. 4861.

[6] «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе
______________________________

___________________________ дан

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
_____________________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган:______________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: _____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
_____________________________________________________________________________________.

Персональ мәгълүматлар эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), блокировкалау, персональ мәгълүматларны юкка чыгару, шулай ук  дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшәртү өчен кирәкле башка гамәлләр, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук минем исемнән эш иткән затның ризалыгын бирәм.


Моның белән раслыйм: минем шәхескә һәм минем исемнән эш иткән затка караган, гаризага кертелгән, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.


Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

| ______________________ | __________ | __________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча
гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




Бүлек башлыгы гаризаны, документларны карап тикшерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә
Карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар
Бүлек белгече мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булуны тикшерә, исәп делосын рәсмиләштерә, мәгълүматларны һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны алу өчен ведомствоара электрон үзара хезмәттәшлек аша электрон рәвештә запрослар җибәрә, һәркем файдалана алырлык сайтлардан мәгълүмат карый.
Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре запрослар нигезендә яисә язма рәвештә соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазе җибәрәләр.
Мәгълүматлар бар
Әйе
Юк
Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре мәгълүматларны бирәләр
Документлар һәм мәгълүматлар
Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре кире кагу турында белдерү кәгазе әзерлиләр
Кагу турында белдерү кәгазе
Бүлек белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек буенча кергән документлар (мәгълүмат) нигезендә карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты
Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсе 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә проекты
Бүлек белгече карар проектын килешенү өчен Бүлек башлыгына җибәрә
Килешенү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән карар проекты
Бүлек башлыгы карар проектын карап тикшерә, килешенә һәм карар проектын килешенү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә
Килешенгән, килешенү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелгән карар проекты
Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы карар проектын (бәяләмә яки баш тарту) карап тикшерә, килешенә яки карар проектындагы (бәяләмә яки баш тарту) кимчелекләр буенча күрсәтмә әзерли һәм аны Бүлек белгеченә җибәрә
Килешенгән һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты яисә Бүлек белгеченә җибәрелгән карар проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмә

Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе төзәтелгән карар проектын (бәяләмә яки баш тарту) карап тикшерә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә

Килешенгән һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты (бәяләмә яки баш тарту)

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:
- ахыргы варианттагы карар проектын (бәяләмә яки баш тарту) тикшерә;
- карар проектын (бәяләмә яки баш тарту) тарату реестрында Башкарма комитет вазыйфаи затларының кирәкле визалары булуны (булмауны) тикшерә;
- карар проектын Башкарма комитет бланкында бастырып чыгара;
- карар проектын (бәяләмә яки баш тарту) имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән Башкарма комитет карары проекты (бәяләмә яки баш тарту)

Башкарма комитет Җитәкчесе Башкарма комитет карары проекты (бәяләмә яки баш тарту) имзалый, аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә

Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән Башкарма комитет карары (бәяләмә яки баш тарту)

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе:
- имзаланган карар проектын Башкарма комитет Җитәкчесенең чыгучы хатлар Реестрында теркәүне;
- карарны Бүлеккә җибәрүне гамәлгә ашыра.

Теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән карар (бәяләмә яки баш тарту)

Бүлек белгече гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын файдаланып, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән карарны (бәяләмә яки баш тату) бирү датасы һәм вакыты турында белдерә

Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү, рәсмиләштерелгән карарны (бәяләмә яки баш тату) бирү датасы һәм вакыты турында белдерү

Бүлек белгече, имза куйдырып, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән карарны (бәяләмә яки баш тату) бирә

Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) имза куйдырып бирелгән карар (бәяләмә яки баш тату).

Бүлек белгече Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында туры килү турында бәяләмә бирү (туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту) хакында мәгълүмат урнаштыра

Бүлек белгече туры килү турында бәяләмәне (туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тартуны) торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра